# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**27 ноябрь, 2022 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 22 ноябрендә 11 сәгатьтә, 2022 елның 25 ноябрендә 11 сәгатьтә, 2022 елның 26 ноябрендә 14 сәгать 30 минутта, 2022 елның 28 ноябрендә 12 сәгатьтә, этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

- җирлек торак пунктлары территорияләрен чүплекләрдән чистарту;
- материаллар сатып алып, сууткәргеч челтәрләрне ремонтлау;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә »

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 409 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -215, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 215 катнашучы тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

- җирлек торак пунктлары территорияләрен чүплекләрдән чистарту;
- материаллар сатып алып, сууткәргеч челтәрләрне ремонтлау;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.» соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башлыгы С.П.Матвеева